| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2017 Казан ш. № 10-128/кс

Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга 2018 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында җиткерелә торган кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар кушымтасында күрсәтелгән кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 10-128/кс карарына кушымта

# Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында җиткерелә торган кайнар суга 2018 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек исеме, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м. | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Әлмәт җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 44,07 | 44,07 | 1868,01 | 1909,11 |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 37,35 | 37,35 | 1583,06 | 1617,89 |
| | Зәй муниципаль районы | | | | |
| 2 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 2.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 36,99 | 38,49 | 1678,99 | 1749,50 |
| 2.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 31,35 | 32,62 | 1422,87 | 1482,63 |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | | | | |
| 3 | «Осиново җылы белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| 3.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 13,31 | 13,59 | 1159,92 | 1208,52 |
| 3.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 11,28 | 11,52 | 982,98 | 1024,17 |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 4 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 4.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып | 23,71 | 23,81 | 1514,00 | 1576,64 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтелде)* | | | | |
| 4.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 20,09 | 20,18 | 1283,05 | 1336,14 |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 5 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 5.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 18,84 | 19,64 | 1678,77 | 1737,53 |
| 5.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 15,97 | 16,64 | 1422,69 | 1472,48 |
| 6 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 6.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 18,84 | 19,64 | 1603,00 | 1670,07 |
| 6.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 15,97 | 16,64 | 1358,47 | 1415,31 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге